ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

14.10.2022                с. Коргуза                03

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге  Егидерево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын   билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең  24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 31 октябренә Югары Ослан районы Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә  һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Егидерево авылында урам яктырткычларны ремонтлау һәм исәпкә алу төеннәрен урнаштыру

«ӘЙЕ»                «ЮК»

3. Егидерево ФАП бинасы янында Егидерево авылы, Үзәк урамы, 28 йорт адресы буенча 9.30 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы                Д.В.Плохов